БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
25 февраля 2022 ел № 109

**«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларына, Контроль-хисап палатасы рәисенә акчалата бүләкләүләр, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 28 апрелендәге 127 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Даими нигездә дәүләт серенә рөхсәте булган гражданнарга һәм дәүләт серен саклау буенча структур бүлекчәләр хезмәткәрләренә социаль гарантияләр бирү турында» 2006 елның 18 сентябрендәге 573 номрлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (2020 елның 21 маендагы редакциядә), «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 13 декабрендәге 1222 номерлы карары, Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларына, Контроль-хисап палатасы рәисенә акчалата бүләкләүләр, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 28 апрелендәге 127 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 17 нче кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә:

**«Татарстан Республикасы кодексының 26 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракларда, күләмнәрдә һәм тәртиптә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль**

**районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладына дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлар белән эшләгән өчен айлык өстәмә түләү күләме һәм тәртибе**

| Айлык процентлы өстәмә түләү | Айлык өстәмә түләү күләме (вазыйфаи окладтан процентларында) |
|---|---|
| «Аеруча мөһим» яшеренлелек дәрәҗәсе булган мәгълүматлар белән эшләгән өчен | 50,0-75,0 |
| «Үтә яшерен» яшеренлелек дәрәҗәсе булган мәгълүматлар белән эшләгән өчен" | 30,0-50,0 |
| тикшерү чараларын үткәрү белән рөхсәт рәсмиләштергәндә, «Яшерен» яшеренлелек дәрәҗәсе булган мәгълүматлар белән эшләгән өчен | 10,0-15,0 |
| тикшерү чаралары үткәрмичә | 5,0-10,0 |
| дәүләт серен саклау буенча структур бүлекчәләрдә эш стажы өчен:<br>1 елдан 5 елга кадәр<br>5 елдан 10 елга кадәр<br>10 елдан һәм күбрәк | <br><br>10,0<br>15,0<br>20,0 |

2. Әлеге карар имза куелган көннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-коммуникация челтәрендә baltasi.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында һәм pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р. Р. Нотфуллин